ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БӘЗӘКӘ АВЫЛЫНДА ХАЛЫК ҖЫЕНЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2019 елның 2декабреннән № 28

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында гражданнар җыены КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Бәзәкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә, 1 һәм 2 группа инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучылар өчен бер тапкыр түләүдән тыш, аны 150 сум итеп билгеләргә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1.Бәзәкә авылы юлларына вак таш җәю

2.Техник күзәтчелек хезмәтләре өчен түләү

3. Бәзәкә авылында кышкы чорда юлларны кардан чистарту

4.Скважина өченкоега төшерелүче насос (алга таба – Погружной насос) сатып алу

5. Триммер сатыпалу

3. Бәзәкә авылының мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында www.mendeleevsk.tatar.ru«Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы Кәшәфетдинов И.И.